**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«27» март 2019 ел № 495

2019 елның 22 мартындагы 491 номерлы «Питрәч муниципаль районының Иҗтимагый Советы турында Нигезләмәне раслау хакында» Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

РФ Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы, 2014 елның 21 июлендәге 256-ФЗ номерлы «Мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 21 июлендәге 256-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру чаралары турында» 2013 ел, 24 октябрь, 793 нче карары белән Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау, мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Иҗтимагый Советы турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. 2019 елның 22 мартындагы 491 номерлы «Питрәч муниципаль районының Иҗтимагый Советы турында Нигезләмәне раслау хакында» Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карарының 2 п. үз көчен югалткан дип танырга

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

Питрәч муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе А. В. Хәбибуллин